СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №30 (7213) | 14 март, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## 17 март — Бөтенсоюз референдумы көне

# Буш сүзләргә карап алданмыйк

«Дуслык» газетасының 2 март санындагы «Көч бердәмлектәме?» дигән баш астындагы мәкаләне укыгач аңа карата үз фикеремне белдерергә булдым. Мәкаләнең авторы Х. Әхмәтов 17 март көнне районда-шларыбызны бердәм Союзга каршы тавыш бирергә чакыра. Мондый чакыру безнең өчен яңалык түгел. Мондый лозунг астында ачыктан-ачык милләтчеләр, сепаратистлар, яңа барлыкка килгән үзләрен «азатлык өчен көрәшүчеләр», «демократ» дип атап йөртүчеләр чыгыш ясыйлар. Минем уйлавымча, халкыбыз властька омтылучы политиканнарның мондый алдавычына эләкмәс дип ышанырга кирәк. Әмма куркыныч юк түгел. Бүгенге сәяси һәм экономик стабильлек булмаганда, деструктив көчләр Советларга каршы йөгәнсезләрчә эшчәнлек җәелдергәндә халыкларның алдануы да бик мөмкин. Моңа юл куймас өчен мондый сепаратизм күренешләренә вакытында отпор бирергә кирәк.

Татарстан халык депутаты Ф. Бәйрәмова Союз һәм Россия составыннан чыгу турында сүз алып бара икән, бу мәсьәләдә дә карашларны ачыклап узу кирәк. Мин Татарстанның РСФСР составына керүенә, анда президентлык идарәсе кертүгә каршы. Ә яңартылган Союз мәсьәләсендә — минем позициям төгәл һәм ачык — аның яклы. Моның сәбәпләре түбәндәгедә. Татарстан союздан тыш яши алмый, чөнки, мәгълүм булганча, башка республикалардан кертелә торган чималга бәйле. Гигант КамАЗ да Союзның төрле регионнарындагы йөзләрчә тәэмин итүчеләреннән башка яши алмый. Бай нефть ятмалары белән дә, читтән аны чыгару һәм эшкәртү өчен тиешле җиһазлар алмаса ТССР башка республика һәм регионнарның кушымтасы гына булып калачак.

Ләкин бүгенге көндә нәкъ әнә шул экономик элементләр өзелә. Республикаларның «суверенитет парады» предприятиеләр, өлкәләр, регионнар арасында дистә елларга килгән экономик бәйләнешләрне өзә, читкә җиһазлар, детальләр һәм башкаларны чыгаруны тыя. Шундый анархия нәтиҗәсендә илебез катастрофа алдына килеп басты. Металлургия, металл эшкәртү, машина төзелеше, текстиль промышленносте һәм аларга бәйле тармаклар туктау алдында тора. Менә шундый киеренке моментта Ф. Бәйрәмова һәм Х. Әхмәтов Татарстанны илдән аеру идеясен хуплап чыгалар.

СССР халык депутаты, галим Денисов ил территориясендә бер-бер артлы суверен дәүләтләр игълан ителүне «тарихи анохранизм» дип атады. Буржуаз парламентларның берсендә дә моңа юл куймыйлар. Буржуаз демократиянең классик үрнәге АКШта, теләсә кайсы штат билгесе суверен хокукларга ия булса да, дәүләттән аерылып чыгу хокукына ия түгел.

Мәкалә авторы укучыларны СССР идарә аппаратын чиксез үстереп аны экономик яктан тотарга сәләтсез дип ышандырырга тырыша. Аныңча, аерым «князьлекләргә» бүленгән дәүләтләрне асрау арзангарак төшә булып чыга инде. Чынында шулаймы соң? Тулы суверенитет — мөстәкыйль дәүләт төзү дигән сүз. Дәүләтнең исә үз атрибутлары: армиясе, тышкы эшләр министрлыгы, чит илләрдәге вәкилләре һәм башкалар була. Аларның һәммәсен налог түләүчеләр исәбенә тотарга туры килә. Моны 20—25 тышкы эшләр министрлыгы барлыкка килде дип күз алдына китерү генә дә чыгымнарның никадәр артуын аңларга мөмкинлек тудыра. Шулай булгач, тулы суверенитетның экономик отыш китермәгәненә төшенү бик җиңел. Суверенитет өчен көрәштә күп җитәкчеләрнең һәм, әйтергә кирәк, бер Ельцинның гына да түгел, «бөеклек» маниясе белән «авыруы» зур урын тота. Ә андыйлар власть өчен көрәшкәндә бернидән: вәгъдә бирүләрдән, республика халкына төрле ташламалар ясаудан, митинглар, политик забастовкалар оештырудан, киеренкелек тудырудан һәм башка чаралардан да тартынып тормыйлар. Шуңа күрә халыкка: «Сак булыгыз, үзегезне алдауга юл куймагыз», — диясе килә.

Мәкалә авторы тыныч вакытта зур армия тотуны шик астына ала. Әмма сугыш булмасына кем гарантия бирә?! Ә армияне сугыш башлангач кына әзерләмиләр. Бүгенге катлаулы техника, электрон приборлар заманасында квалификацияле хәрби белгечләр хәзерләү өчен айлар, еллар кирәк.

Армиягә каршы фикерләрендә иптәш Әхмәтов ялгыз түгел. Аның фикердәшләре арасында солдат аналары һәм төрле хәрәкәт, оешмалар вәкилләре дә бар. Алар барысы ССР Союзының бердәмлегенә, Советларга каршы булган либераль, монархистик, демократик партияләр йогынтысы астында эш итәләр. Аларның бер ише яллангаи, икенчеләре ирекле армия төзү идеясен күтәреп чыга. Бүгенге көндә без мондый юллар белән бара алмыйбыз әле.

17 мартта үтәчәк референдумга килгәндә, Ф. Бәйрәмова һәм Х. Әхмәтовның яңартылган күпмилләтле Союзга каршы чыгышы халык интересларына каршы килүен бәян итәр идем. Һәм, бер үк вакытта райондашларымны бердәм Союз составында калырга, ягъни «әйе» дип тавыш бирергә чакырам.

**П. НИКУЛИН,**
1942 елдан КПСС члены. Норлат шәһәре.

## РАЙОН СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНДА

11 мартта район Советы председателе Х. Х. Морадыймов җитәкчелегендә район Советы президиумының чираттагы утырышы булып үтте.

Анда районда Бөтенсоюз референдумы көненә хәзерлекнең барышы һәм алда торган бурычлар турында район Советы президиумы председателе урынбасары Т. А. Назарова чыгышы тыңланды. КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков район хуҗалыкларында язгы кыр эшләренә хәзерлек буенча бурычларга тукталды.

Президиум утырышында район колхоз-совхозларында сөт җитештерү мәсьәләсе тикшерелде. Кайбер хуҗалык җитәкчеләренең, белгечләрнең бу мәсьәләгә карата игътибарсызлыгы билгеләп үтелде.

Президиум каралган мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул итте.

Утырышта район тормышына кагылган башка мәсьәләләр дә каралды.



Элек-электән халыкта май язу осталары булган. Аларга хезмәтенә күрә таләпләр дә куелган: май язучы хатын-кыз беренче чиратта бик пөхтә, чиста булырга тиеш дигәннәр. Аның кулы җитез, күңеле сабыр, холкы түзем булуны мәгъкул күргәннәр — ул язган майның тәме шуларга да бәйле дип фараз иткәннәр. Әлбәттә, үз гаиләсе өчен гөбедә май язучылар хәзер көннән-көн азая бара. Әмма табыннарыбызга май җитештерүче остага булган төп таләпләр һаман да элеккечә кала. Норлат сөт-май комбинатының май ясау цехында эшләүче Минзатия Мирзакай кызы Зибаева нәкъ менә шундый сыйфатларга ия булган оста. Моннан тыш ул цехтагы җиһазлар белән дә көйле эшли. Минзатияне пөхтә, төгәл, тыйнак хатын буларак коллективта ихтирам итәләр. Ул эшли торган цех продукция җитештерү буенча 1990 ел планын уңышлы үтәгән иде. Узган ике айда да алар сынатмадылар. Ә хәзерге вакытта беренче квартал нәтиҗәләрен яхшырту өчен тырышалар.

Рәсемдә: май ясау цехының әйдәп баручы остасы — Минзатия Мирзакай кызы Зибаева.

## Чагыштырып кара

Монда ике төрле уйлап, ике төрле сөйләп торырлыкмы соң инде? Әлбәттә, Союз яклы мин, бердәмлек яклы. Әгәр элеккечә бердәмлек булса, татулык хөкем сөрсә, илебездә кан коюлар да булмас иде. Гөнаһсыз сабыйларның яше аз коелдымы әллә? Гаепсез кешеләрнең каны азмы түгелде? Әрмәннәрнең, осетин яки грузиннарның гаебе нидә соң? Минем татар булуым һәм руслар-чувашлар арасында яшәвем шулай ук гаепмени соң? Уйлап карасаң — баш җитми. Менә минем кызым үсә. Аның кебек үк зифа сынлы кыз баланы Балтыйк буенда танк таптап үтә... Кайсы ана шундый хәсрәткә күз йома алыр икән? Кем үзенә шундый үзәк өзгеч хәл килүен теләр микән? Беребез дә теләми бу хәлләрне. Бүген башбаштаклыкның һәм фаҗигаләрнең нигезе — Союзны сакламауда дип уйлыйм мин. Ата белән анага, әбибабага, туганнарга карата үзара ихтирам булмаган гаиләдә нинди тәртип булсын соң? Безнең илдә дә нәкъ шулай килеп чыкты. Бердәмлек булсын! Шул вакытта кан-яшь түгәргә сәбәп калмас. Балаларыбыз хакына Союзны саклап калыйк!

**Н. КАНӘФИНА,**
рентгенлаборант.

## Участогымда эшлим

Мин 17 мартта булачак Бөтенсоюз референдумында катнашырга тиешле үз участогыма беркетелгән кешеләрне йөреп чыктым. Бу эш белән бездә егермедән артык агитатор шөгыльләнә. Без беренче тапкыр мондый ил күләмендәге чарада катнашабыз. Шуңа күрә өлкән буын вәкилләре арасында референдумның ни икәнен аңламаучылар да бар әле. Шуны төшендерергә, аңлатырга тырышам. Мин агитатор буларак үз фикеремне көчләп тагарга җыенмыйм. Шулай да, «Сез ССР Союзының сакланып калуын кирәк дип саныйсызмы?» дигән соравыма күп вакыт «Әйе» дигән җавап ишетергә туры килә.

Димәк, зур күпчелек тигез хокуклылыкны яклап чыга. Хокукларыбыз тигез булганда гына илебезне бүгенге авыр хәлләрдән чыгарырга мөмкин. Мин үземнең участогымнан референдумда катнашучыларның Совет Социалистик Республикалар Союзының бердәмлеген яклап тавыш бирерләр диеп уйлыйм.

**Р. ГАЛЛӘМОВА.**
Киекле урта мәктәбе.

## АПО үзгәртеп корылды

11 мартта колхоз-совхозларның һәм агропромышленность комплексы составына кергән предприятиеләр, оешмалар вәкаләтле вәкилләре җыелышы булып үтте.

Җыелыш «Татарстан ССР Министрлар Советы структурасында үзгәрешләр турында» һәм «Татарстан ССРның Министрлар Советы турында» Татарстан ССР Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында 1991 елның 7 февраль Законы нигезендә, Татарстан ССР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы төзү, аграр промышленность тармагына идарә итүнең дәүләт формасына күчүен исәпкә алып, уполномоченныйлар җыелышы Октябрь АПОсы советының вәкаләтләрен туктату турында карар кабул итте. Карар нигезендә агропромышленность берләшмәсенең район советының эшче аппараты һәм ревизия комиссиясе бетерелде.

Җыелышта агропромышленность мәсьәләләре белән шөгыльләнү өчен район авыл хуҗалыгы идарәсе төзелүе игълан ителде.

# Икеләтә бәйрәм булды

**Язның беренче ае район чөгендерчеләренә ике бәйрәм китерде. Нәкъ 8 Март алдыннан гына районда чөгендерчеләр слеты үтте.**

«Норлатнефть» НГДУсының спорт комплексы бәйрәмнәрне күп күргән. Менә бүген дә аның киң, биек залында күңелле сөйләшү, җанлы аралашу, бәйрәм алды ыгы-зыгысы. Җәй буе чөгендер басуларыннан кайтып кермәгән, көзге көйсез һавада да кырны ташламаган чөгендерче апайлар, механикалаштырылган звено җитәкчеләре—бүгенге бәйрәмнең төп кунаклары.

—Слетның нәкъ 8 Март алдыннан оештырылуы тикмәгә түгел. Чөнки чөгендер игү кебек катлаулы хезмәт нигездә хатын-кызлар җилкәсенә төшә,—дип башлады үз чыгышын район Советы рәисе, КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов. чөгендерчеләр турында үтә бер җылылык һәм хөрмәт белән сөйләп. Әйе, чөгендерчеләр моңа лаеклар. Узган катлаулы елда да алар 6580 гектар мәйданда 111000 тонна татлы тамыр үстереп дәүләткә тапшырдылар. Аларның катлаулы хезмәте, мул уныш үстергән хуҗалыклар турында слетта КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков сөйләде.

Һәм менә сәхнәдә—алдынгылар. Бу юлы аларның парадын хатын-кызлар звенолары башлады. «Кондырча» колхозының Рәисә Искәндәровна Сафина җитәкчелегендәге 6 кешедән торган звено һәр гектардан 345 әр центнер татлы тамыр үстереп, аны дәүләткә сату планын 164 процентка үтәде. Слет нәкъ аларны хөрмәтләүдән башланды да. Хафизов исемендәге колхоздан Гамбәр Шәфыйковна Җәлалова, Мичурин исемендәге колхоздан Марина Геннадьевна Гаврилова, «Үрнәк»тән Затия Вәлиевна Әхмәтова звенолары да бу тантанада хезмәтләре өчен зур бәя алдылар.

Хатын-кызларны алдынгы механикалаштырылган звено җитәкчеләре алыштырды. Ульянов исемендәге колхоздан Сәфәргали Сәгыйрович Галимов звеносы һәр гектардан 292 центнер татлы тамыр үстерде, аны сату планын 260 процентка үтәде һәм район ярышында беренче урынны алды. «Большевик» колхозыннан В. Н. Яковлев һәм Мичурин исемендәге колхоздан Г. С. Петров звенолары да алардан күпкә калышмыйлар. Ә аренда коллективлары арасында «Кондырча» колхозыннан Минсәлих Әхмәтсафович Гомәров звеносына тиңнәр булмады. Әлеге звено үз карамагындагы 90 гектар мәйданда һәр гектардан 341 әр центнер татлы тамыр үстерде һәм алгарак китеп булса да әйтик: бу күрсәткеч хуҗалыкка районда иң югары уныш алып, 1 урынга чыгарга да бик нык ярдәм итте. II—III урыннарны Хафизов исемендәге колхоздан Рәхимҗан Рәисович Насыйбуллин (ул хәзер «Алга» колхозы председателе) һәм «Рассвет» совхозыннан Касыйм Минәхмәтович Сатдаров звенолары алдылар.

Слет бик күпләргә җиңү һәм хөрмәтләү шатлыгы китерде. Шикәр чөгендере игү буенча иң алдынгы механизаторлар исеменә лаек булган Сәлимҗан Галимҗанович Гыймалетдинов һәм Нәфыйк Кашапович Җәләлетдинов («Чишмә»), Нурислам Мирсәетович Җамалетдинов һәм Газинур Мингазыймович Галәветдинов («Москва»), Владимир Петрович һәм Николай Петрович Мандрейкиннардан («Россия») соң сәхнәгә һәр хуҗалыкның диярлек чөгендер игү осталары чыктылар. Алар хөрмәтенә җыр яңгырады, бүләкләр тапшырылды.

Чөгендер үстерү күп кешеләрнең хезмәтен берләштерә. Чөгендер төяүчеләр Исхак Касыймович Фәйзуллин («Рассвет» совхозы), Валерий Васильевич Илюхин (Хафизов исем.), Хаҗиәхмәт Минәхмәтович Сәгыйров («Чишмә») бу төр хезмәт буенча районда иң алдынгылар булдылар. Ә шикәр чөгендерен ташуда «Татарстан» колхозыннан Фаяз Вәгыйзович Мингалимов, «Рассвет» совхозыннан Рөстәм Хәмзиевич Гобәйдуллин, Ульянов исемендәге колхоздан Әхәт Әсгатович Мөхетдинов өлгерлекләренә ничек соклanмыйсың ди? Фаяз Вәгыйзович үзе генә дә КамАЗында 49840 тонна-километр юл үткән. Бу эштә хуҗалыкларга ярдәмгә килгән шоферлар турында да җылы сүзләр булды слетта. Ремонт-техник предприятиедән Геннадий Александрович Шпак, НУРБдан Әмир Хәсәнгатович Мөхәммәтшин, технологик транспорт идарәсеннән Валерий Павлович Убамзаров, аларның иң алдынгылары буларак, шулай ук слетта катнаштылар. Тантанада шикәр чөгендере игүдә ярдәмне оештыручы район элемтә узелы, көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе, саклык банкы кебек коллективлар да, аны эшкәртүче шикәр заводы эшчеләре рәхмәт хисләре белән телгә алындылар.

Һәм, ниһаять, слетның иң тантаналы өлеше килеп җитте. Алда әйткәнебезчә, чөгендер игүдә район хуҗалыклары арасында социалистик ярышта «Кондырча» колхозы җиңеп чыкты. Бу хуҗалык чөгендерчеләре 160 гектар мәйданда гектарыннан 289 шар центнер татлы тамыр үстереп, аны дәүләткә сату планын 157 процентка үтәделәр. Күчмә Кызыл байрак нәкъ шул хуҗалыкка тапшырылды.

II урынга Хафизов исемендәге колхоз чыкты. Хуҗалык чөгендерчеләре һәр гектардан 275 әр центнер продукция үстерделәр. Мичурин исемендәге колхоз чөгендерчеләре, 266 шар центнер продукция үстереп, ярышта өченче урынга чыктылар.

Ниһаять, котлаулар тәмамланды, җырлар тынды. Җырлар димәктән, бу юлы колхоз уңганнарын котларга авыл үзешчәннәре килгәннәр иде. Слетта катнашучылар Якушкино авылыннан Дмитрий Алякимов, Кычытканлыдан Дания Мансурова һәм башкаларның чыгышларын бик җылы кабул иттеләр. Ә ахырдан, Х. Х. Морадыймовның йомгаклау сүзеннән соң, залга ал-кызыл лалә чәчәкләре тотып ир-атлар чыкты. Бу хатын-кызлар бәйрәме алдыннан хөрмәтле чөгендерчеләрне гаҗәеп олылау, аларга хезмәтчән буларак та, ана һәм хатын-кыз буларак та тирән ихтирам билгесе иде. Кичәне оештыруга күп көч куйган, чөгендерчеләргә бәйрәм пакетлары әзерләгән, өстәл җыйган, слетта аларга хезмәт күрсәткән җәмәгать туклануы, НГДУ һәм урман промышленносте хуҗалыгы ОРСы хезмәткәрләре дә шундый ук хөрмәтләргә лаек булдылар. Болар һәммәсе болай да күтәренке рухта барган слетны тагы да ямьләп җибәрделәр.

Ә иң ахырдан традицион лотерея уеннары булды. Бәхетлеләр чит илдә эшләнгән жакетлар, җылы ботинкалар, аш сервизлары, кул сәгатьләре һәм башка кыйммәтле отышлар белән тараддылар.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**



Зоя Никифоровна Захарова (рәсемдә)—Мичурин исемендәге колхозда тәҗрибәле чөгендерче. Күп еллардан бирле җәй көннәрендә ул бу четрекле культураны үстерүдә эшли, үз мәйданыннан мул уңыш үстерә. Узган ел да ул үзенең 4 гектарлы участогында гектарына 321 әр центнер татлы тамыр алды.

Зоя Никифоровна көзге эшләр тәмамлангач, гадәттә терлекчелеккә эшкә килә. Быел исә колхозда төрле эшкә йөри. Карусыз, һәр эшкә бөтен тырышлыгын куеп хезмәт куярга гадәтләнгән КПСС члены З. Н. Захарова биредә дә иң актив, иң алдынгылардан.

## „Бик яхшы"га бәяләделәр

**Яшь туристларның район станциясе каршында эшләүче 30 филиалның берсе —шәһәрнең өченче урта мәктәбендә. Аңа А. И. Абрамов җитәкчелек итә. Узган сишәмбедә ул станциянең «Яшь турист» түгәрәге җитәкчеләре өчен ачык занятие үткәрде.**

Занятие уңышлы үтте. Моңа, берьяктан А.И. Абрамовның үсмерләр белән эшләүдә зур тәҗрибәсе ярдәм итте.

Ул көнне шикәр заводы поселогы халкы гадәти булмаган күренешкә тап булды. Мәктәп янына җыелган халык төркем-төркем булып берничә юнәлеш буенча киттеләр. Берәүләрнең кулларында компаслар, маршрут кәгазьләре, икенчеләре гәүдәләрен солдатларча төз тотып атлыйлар: адым санаулары иде егетләрнең. Урында ориентлашу, азимут буенча йөрү занятиесе шулай башланды. Һәр группаның үз маршруты. Әнә, түгәрәк членнары Э. Нәфыйгов, А. Кутишев, Р. Хөсәенов, С.Кутишев, И. Еремеев, С. Абрамов, Ю. Калуков компас белән ничек яхшы эш итәләр, схеманы дөрес төзиләр. В. Кулагин, Х. Җамалетдинов, С. Федотов, Э. Хәлиуллин, Р. Әбҗәппаровның азимут билгеләве, ориентир сайлап ахыргы ноктага бик төгәл барып чыгулары өлкәннәр күңелендә соклану уятты.

Түгәрәкләр җитәкчеләре ачык занятиене «бик яхшы» дип бәяләделәр. А.И. Абрамов аларның теоретик сорауларына җавап бирде.

—Түгәрәккә йөрүче балалар белән ничек эшлисез?

Александр Ивановичның җавабы әзер. Иң элек балаларны ул гади үсмерләр генә итеп түгел, ә бәлки киләчәктә безнең тыныч тормышыбыз сагында торачак егетләр итеп күз алдына китерә. Түгәрәк занятиеләре дә шулардан чыгып оештырыла.

**Р. ИБРАҺИМОВА.**

# Иң элек—хатын-кызлар шат

## 8 март көнне шәһәрнең сәүдә үзәгендә бәйрәм ярминкәсе үтте

**—Игътибар иттегез микән? Ярминкәдә гел диярлек ир-атлар сату итте бит!**

**—И, аның каравы, товар алучылар гел хатын-кызлар иде. Кайсы капчык күтәргән, Кайсы янчык. Гел хатын-кызга кирәк бит!**
**(Ярминкәдә сөйләшүләрдән).**

Әйе, шул! 8 Март — бәйрәм көне дә аларны бу елына килгән бердәнбер мәшәкатьләрдән азат итә алмаган. Хәер, хәзер хатын-кыз алырга әйбер булуына күбрәк куана, кай ул вакыты һәм көне белән исәпләшеп тору! Шуңа да бәйрәм көнне базар ыгы-зыгысы хатын-кызларның кәефен төшермәгән иде.

Ә алырга әйберләр байтак иде ярминкәдә. Сыер, сарык, дуңгыз ите янына халыктан җыелган каз, үрдәк белән дә сату итүчеләр булды. Бәяләре телевизордан күреп халык өйрәнгәнчә түгел—5—8 сум. Бәрәңге, суган, кишер, чөгендер, борчак, он, бал, карабодай һәм башкалар —һәммәсе табынга кирәк нәрсә. Шуңа да сәүдә гөрләп барды. Әнә «Большевик» колхозы сатарга дуңгыз балаларын да алып килгән. Комбайнчылар гадәттәгечә һәр товарны үлчәп, төреп алып чыкканнар —биредә шуңа чират бигрәк тә тиз үрли. «Лесная Поляна» һәм «Знамя Октября» колхозлары мунча себеркесенә хәтле китергәннәр. Бәйрәм кәефе сәүдә белән килгән машиналар янында әллә кайн сизелә; күпләре хуҗалыкларын күрсәткән язу янына хатын-кызларга бәйрәм белән котлаулар да язып элэргә онытмаганнар.

Райпо кибетләре, җәмәгать туклануы предприятиеләре рәтеннән читтәрәк сәүдә итәргә чыккан промышленность предприятиеләре машиналары тезелгән. Бу юлы районны шаккаттырганы сөт-май заводы булгандыр. Атнасы-атнасы белән каймак та ала алмаган шәһәрлеләр сөт эсте, 4 процентлы кайнатылган сөт, корт, сыр, май кебек сирәк күренә торган продукция алып сөенделәр.

—8 төрдә 3163 сумлык продукция саттык,—диделәр сөт-май заводында безгә. Аларга хаклы рәвештә беренче урын бирелде дә. Икмәк заводы да бу көнне халыкны өч төрле продукция белән шатландырды.

Ярминкә үткәрү комиссиясе ярминкәдә барлык хуҗалыкларның да актив катнашуын билгеләп, колхоз-совхозлар арасында беренче урынны «Рассвет» совхозына бирергә карар итте. Алар бу көнне 3 центнер ит, 5 центнер колбаса, 5 центнер борчак, 2,5 центнер бәрәңге, 3 центнер кишер, 1 центнер чөгендер, 20 килограмм май, сөт саттылар.

Икенче урынны Хафизов исемендәге, өченчене «Большевик» колхозлары алды. Хафизовлылар 2 центнер сыер ите, 1 центнер дуңгыз ите, 2 центнер он, 2 центнер борчак, 1 тонна бәрәңге реализацияләделәр.

Ярминкәдә авыллардан килгән үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның концерты да үткәрелде.

—Ярминкәдә байтак суммада авыл хуҗалыгы продуктлары, промышленность товарлары реализацияләнде. Ул алдагы ярминкәләр белән чагыштырганда күпкә тәртипле, тыныч үтте,—диде район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары А. И. Газизуллин.

Димәк, шәһәрлеләрнең бәйрәм өстәлен сый-нигъмәтләр өстәлде диген сүз. Һәм, әлбәттә, моңа иң элек бәйрәм сәбәпчеләре, хатын-кызлар шат булды!

**С. НУРУЛЛИНА.**

